# СТӘРЛЕБАШ чишмәләре

Тынычлык һәм бәхет сезгә!

Гәзит 1932 елдан чыга.

Башкортстан Республикасы Стәрлебаш муниципаль районы иҗтимагый-сәяси гәзите

http://sterlibashevskierodniki.ru

http://admsterlibash.ru/- Стәрлебаш муниципаль район хакимияте сайты

№ 110 (9678)

Сишәмбе, 22 сентябрь, 2015 ел


## Бәхет, тынычлык һәм изгелек телибез!

Хөрмәтле Стәрлебаш районы мөселманнары!

Сезне изге Корбан бәйрәме уңаеннан кайнар котлыйм!

Элек-электән бу көнне мөселманнарның мохтаҗларга ярдәм итү, туганнары һәм якыннары турында хәстәрлек күрү кебек изге гамәлләре чагыла. Корбан бәйрәмендә һәр кеше, әрвахлар олы яшьтәгеләр, аз тәэмин ителгәннәр, чирлеләр һәм ялгызлар үзләренә карата игътибар тойсын.

Барлык район халкын шушы изге бәйрәм белән чын күңелдән котлап, нык сәламәтлек, тынычлык, бәхет һәм иминлек телим. Күңелләрегездә якты өметләр, сөенеч, миһербанлылык уянсын, киләсе көнгә ышаныч артсын.

**Ф.З.ТУКТАРОВ,**
*Стәрлебаш муниципаль район хакимияте башлыгы.*

## Гражданнарны яклау айлыгы бара

Агымдагы елның 4 сентябреннән алып 4 октябрәнә кадәр республикада гражданнарны яклау айлыгы үткәрелә. Аның бурычлары – авария һәм гадәттән тыш хәлләрдә халыкка ничек эш итәргә өйрәтү, идарә итү органнарының, гражданлык оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм чиклау бердәм дәүләт системасы көчләре һәм чараларының әзерлеген камилләштерү, аларны гадәттән тыш хәлләрне чикләүгә әзер тотү, авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне башкару.

Октябрь аенда башкарма властьның федераль органнары территориаль органнары, республика башкарма власть органнары, урындагы үзидарә органнары, республика оешмалары белән гражданлык оборонасы буенча Бөтенрусия тренировкалары үткәрү планлаштырыла.

## Милек салымнарын түләү вакыты чыгуга




көн калды

*Блиц-сорашу*

## Мин салымнарны түлим, чөнки...

**Тәлгать Исмәгыйлев, элекке физкультура укытучысы, Табылды авылы:**

- Моңа кадәр «Салымнар кая китә?» диган сорау туганы булмады, район гәзите санының берсендә бу сорауны күтәргәч, җавабын Интернеттан эзләргә булдым. Урындагы салымның шулкадәр киң кулланылуын белми идем. Бу урындагы үзидарә органнары карамагында булган урындагы үзидарә органнарын, сәламәтлек саклау, мәдәният, торак-коммуналь өлкәсен, физик культура һәм спортны һ.б. тәэмин итү. Шулай ук территорияларне яшелләндерү, калдыкларны утильләштерү, янгынга каршы хәвефсезлекне тәэмин итү, максатлы программаларны тормышка ашыру, муниципаль

*Район агросәнәгать комплексында*

## «Татлы тамыр» әче тир белән үстерелә

Үткән атна уртасында ук Ленин исемендәге хуҗалыкның чөгендер басуында мал азыгы җыю комбайннары гүләп эшкә тотынды. Быелгы елда Ленин исемендәге хуҗалык эшчәннәре 180 гектар мәйданда шикәр чөгендере эшкәртә. Беренче көнне басуга бер генә звено чыккан, икенче көненә исә икенчесе кушылган.



